РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Сармановский муниципальный район
Совет
Азалаковского сельского поселения
423371 с. Азалаково ул. Зеленая дом 8В
Телефон ( 85559) 4 – 80 – 36

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге
Советы
423371 Азалак авылы Яшеллек ур. 8В йорты
Телефон ( 85559) 4 – 80 – 36

ОГРН 1021601313381, ОКПО 93068255, ОКАТО 92253804000,
ИНН/ КПП 1636001386/163601001,ОКТМО 92653404

РЕШЕНИЕ
№38

КАРАР
21.04.2022г.

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Азалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 13 маендагы 7 номерлы Азалак авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 11 декабрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы нигезендә Азалак авыл җирлеге советы карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Азалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 13 маендагы 7 номерлы Азалак авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 2 пунктында «шулай ук» сүзләрен, «шулай ук федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү тәртибендә каралган Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бюджет кредитлары бирү максатларында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Азалак авыл җирлеге
Советы рәисе

И.Г.Габдулгазизов